# УЙЛАГАННАРЫМНЫ ЯЗАМ...

Язганнарыңда башкаларга бәя бирүдән дә авыр әйбер юктыр, мөгаен. Иң мөһиме, җиде кат уйлап, бер кат язарга кирәк. Фикерләреӊ гадел дә булсын, урынлы да булсын. Әйтергә теләгән сүзләреӊ төгәл, килешле һәм образлы да булырга тиеш! Син бит фикерләреңне үзең өчен генә язмыйсың, ә меңләгән укучыга да җиткерәсеӊ. Дөресрәге, алар өчен язасың.

Әдәбиятта да, матбугат дөньясында да күптән эшләгәнгә күрә, башкаларга карата үз сүзләреңне һәрвакыт әйтеп барырга, үз мөнәсәбәтеңне белдереп торырга туры килә. Ул сүзләр сәхнәдән, радио эфирларыннан, телевизор экраннарыннан әйтелергә мөмкин. Юбилейларда, иҗат кичәләрендә, ниндидер премияләргә тәкъдим ителгәндә, кемнәрнеңдер китабы чыккач... Шунсыз мөмкин дә була алмый, чөнки син шул мохиттә яшисең, йөзләгән кеше белән аралашасың, аларның кылган гамәлләрен, халык алдындагы хезмәтләрен күрәсең, иҗатларын күзәтеп барасың...

Әлбәттә, башкаларга тик торганнан гына, бер сәбәпсез генә мөнәсәбәтеңне белдерү ничектер сәеррәк кебек. Шуңа күрә дә бик күп мәкаләләрем газета-журналларның соравы буенча, кемнәрнеңдер үтенече яки төрле юбилей мөнәсәбәтләре белән язылды. Күңел кушканга язылганнары да шактый урынны алып тора. Алар арасында гомер буе аралашкан каләмдәшләр, остазлар һәм шәкертләр, үзем яраткан һәм хөрмәт иткән классиклар, рәссамнар, композиторлар, җырчылар, матбугат әһелләре, якташлар, дуслар һ. б.

Язганнарым төрле жанрда иҗат ителгән: араларында иҗат портретлары да, юбилей мәкаләләре дә, китапларга бәяләмәләр дә, Язучылар берлегенә тәкъдимнамәләр дә җитәрлек. Әдәби журналларда басылганнары да, балалар газетасы өчен махсус язылганнары да очрар, кульязма хәлендәге китапларга күзәтүләрне дә табарга мөмкин... Ләкин ничек кенә булмасын, алар ихластан, зур җаваплылык хисе тоеп язылганнар. Шунысын да әйтеп китим: үземнең язмаларымда мин шәхесләрнең иҗатларына һәм куйган хезмәтләренә гадел бәя бирергә тырыштым. Беренче карашка, алар гел мактауларга гына корылган булып тоелырга мөмкин. Ләкин игътибар беләнрәк укып карасаң, анда тәнкыйди карашларны да, әсәрләргә җитди анализны да, әдәби-мәдәни бәхәсләрне дә табып була.

Әмма шунысы да бар: гомер буе иҗатчылар даирәсендә кайнагач, аларның төрле кыланмышлары, тормышта, яшәештә үз-үзләрен тотышлары белән шактый еш очрашып торгач, кемнең кем икәнен яхшы беләсең. Күп очракта әдәбият-сәнгать әһелләренең (язучының, рәссам, җырчы, композиторның) әсәрләре халык арасында бик популяр булган очракта да, аның укучыда кире тәэсир тудыра торган начар сыйфатлары да булуы бар. Андый мисаллар буа буарлык… Мин аларны бик яхшы беләм, кайберләрен үз җилкәмдә татыганым бар. «Пәри башка, җен башка» дигән шикелле, һәр язманың үз вазифасы, үз максаты була. Аннары белгән, күргән бөтен әйберне, күңелеңдә йөргән бөтен уй-фикерләрне бер мәкаләгә сыйдырып та бетереп булмый. Кем белә, киләчәктә башка төрлерәк язмаларым да дөнья күрер әле. Эч пошырган күренешләрне, гайрәтне чигергән каләмдәшләрне, бер киртәгә дә сыймый торган үзара мөнәсәбәтләрне, чиркангыч вакыйгаларны күргән саен, кул кычытып торган чаклар еш булгалый…

Ә бу язмаларым — башкаларга бер карашым, аларга булган мөнәсәбәтем. Кайберәүләр минем белән килешмәскә дә мөмкин, аларның башкача уйлаулары да бик табигый. Мин исә үземчә уйлыйм, үземчә фикер йөртәм, шул фикерләремне, кулымнан килгәнчә, укучыларыма җиткерергә тырышам. Шул гына…

I

# ПРЕЗИДЕНТ ШУНДЫЙ БУЛА!

## МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ



Илләр белән императорлар, патшалар, корольләр, ханнар, президентлар хакимлек итә. Элек татарда да ханнар булган. Болгар ханнары, Себер, Кырым ханнары, Казан ханнары. Бүген исә безнең үз Президентыбыз бар.

Ул — бердәнбер! Бөтен Татарстанга, бөтен татар халкына бирәү генә! Ул башка хөкүмәт җитәкчеләреннән күп яклары белән аерылып тора. Төс-кыяфәте, үз-үзен тотышы, сөйләшүе, фикер йөртүе белән дә. Хәтта исем-фамилиясе белән дә. Бар микән татарда тагын шундый исем, шундый фамилия? Үзе — Минтимер, үзе — Шәймиев! Коеп куйган татар! Чалымнарында бүгенгелек тә, борынгылык та чагылып китә. Татар авылы традицияләрендә үскәне, Европа тәрбиясе алганы, Шәрык серлелеген, тапкырлыгын үзенә туплаган олы бер шәхес икәнлеге әллә каян күренеп тора.

Туган якларыма кайтканда, мин һәрчак аның авылы янынннан узып китәм. Казан — Уфа юлы өстендә ул. Актаныш районына килеп кергәннән соң, тауга күтәреләсең дә, бераз баргач, Пучы авылы күренә. Аннары — Әнәк. Татарга зур-зур шәхесләр биргән кечкенә Әнәк авылы. Мин аны элек фронтовик-шагыйребез Нур Баян туган изге бер авыл дип кенә белә идем. Баксаң, шагыйрь Рахмай Хисмәтуллин да шунда туып үскән икән. Бер биргәнгә бирә бит ул Ходай! Хәзер инде Әнәк — Татарстан Республикасының Беренче Президенты туган авыл да! Татар тарихына мәңгелеккә кереп калачак бәхетле, үлемсез авыл! Татар шагыйрьләре авылда туа, диләр иде, татарның президентлары да авылда туа икән бит. Хәер, Минтимер аганың үзендә дә шагыйрьлек бардыр, мөгаен. Шулай булмаса, туган җирен, туган авылын, малай чакларын шагыйрьләр кебек өзелеп сагынмас иде…

Ул шул кечкенә авылда туган, шунда үскән, күршедәге Пучыда урта мәктәпне тәмамлаган. Татар мәктәбен, әлбәттә. Казанда авыл хуҗалыгы институтында укыганнан соң, күрше Мөслим, Минзәлә районнарында хезмәт юлын башлаган, эшкә өйрәнгән.

Татарлык, авыллык аның канында, җанында, рухында. Ни кызганыч, совет чорында без, нигездә, русча сөйләшүгә күчеп беткән идек. Мәктәпләрдә, җәмәгать урыннарында, бигрәк тә югары даирәләрдә татарча сөйләшү «культурасызлык» булып санала иде. Шуңа күрә җитәкчеләребез үз туган телләрендә бөтенләй сөйләшмәс булдылар, һәрхәлдә, без аларны бары тик русча гына аралашалардыр дип белә идек. Минтимер Шәймиев турында да күпләр шулай дип уйлый иде. Әмма төрле җыелышларда, сессияләрдә татарча сөйләшүне иң беренче булып ул кертеп җибәрде. Моннан берничә ел элек мин Президент турында «Ихлас» дигән телевизион тапшыру эшләгән идем. Ул анда бер сәгать буена фәкать татарча сөйләде. Матур итеп. Саф татарча. Бернинди дә рус сүзләре кушмыйча гына. Халык өчен көтелмәгән ачыш булды бу. Бигрәк тә Татарстанның башка җитәкчеләре өчен. Шул тапшырудан соң алар да, тырыша-тырыша, татарча сөйләшә башладылар, һәм, әйтер идем, ярыйсы гына «сукаларга» өйрәнеп киләләр.

Минтимер Шәймиев, — әйткәнемчә, түбәннән, авылдан күтәрелгән кеше, эш кешесе, җир кешесе, игенчеләр нәселеннән. Җирне, авыл хуҗалыгын, гомумән, Татарстанны, аның кешеләрен яхшы белә. Заманында республикабызның бөтен төбәкләрен дә йөреп чыккан, кешеләре белән аралашкан, эшләре, яшәешләре белән танышкан. Кайсы гына районга, кайсы гына авылга барып чыкса да, үз кеше ул. Аны үз итәләр, яраталар. Аңа ышаналар, өмет белән карыйлар. Мондый авыр, катлаулы заманда, республика халкының ышанычын аклау өчен, сабыр холыклы, ныклы ихтыярлы, фидакяр һәм акыллы булу кирәк. Минтимер Шәймиев нәкъ шундый кеше!

Татарстан халкы Президентыннан уңды. Бу үзгәрешләр чорында безнекедәй зур республика белән хакимлек итү, халыкларның иминлеген тәэмин итү, ызгыш-талашларга юл куймау һәм, бернинди каршылыкларга да карамастан, мөстәкыйльлеккә юл тоту, үз юлыңны табу, үз йөзеңне саклап кала алу — зур каһарманлык. Күреп торабыз: боларның берсе дә җиңел генә бирелми.

1990—1991 елларда, Югары Совет Президиумы әгъзасы буларак, миңа Минтимер Шәрип улы белән турыдан-туры бергә эшләргә туры килде. Республикабызның мөстәкыйльлеге өчен көрәшнең башланган гына чагы иде әле. Кайсы юлдан китәргә? Сәяси тәҗрибә дә аз. Үзәк тә коточкыч каршылык күрсәтә. Күрше республикаларның тыны да чыкмый. Республиканың үз эчендә дә каршылыклар җитәрлек. Ләкин Минтимер Шәймиев җитәкчелегендәге Югары Совет югалып калмады. Бөтен каршылыкларга да карамастан, мөстәкыйльлек турында Декларация кабул ителде. Бу — мөстәкыйльлеккә беренче һәм хәлиткеч адым булды. Минтимер Шәймиевнең беренче зур сәяси җиңүе дә иде ул. Сессия һәм Президиум утырышларында мин аның нинди тыныч, төгәл, принципиаль җитәкче, көчле рухлы шәхес икәнен күрдем. Депутатларны да тыңлый, киңәшләргә дә колак сала. Әгәр дә хаклы булуына инана икән, үз сүзен уздыра да ала... Декларация һәм Конституция кабул иткәндә дә, Референдум уздырганда да, Россия белән каршылыклар килеп чыкканда да нәкъ аныңча булды. Сәясәттә компромиссларга да бара белергә кирәк икән. Шунсыз ерак китә алмыйсың. Безнең Президент бу хакыйкатьне яхшы аңлап эшли. Россия белән Татарстан арасында төзелгән Шартнамә моның ачык бер мисалыдыр. Шушы Шартнамә безнең бүгенге



тыныч тормышыбызны, гомумән, республикабызның мөстәкыйльлеген саклап калырга ярдәм итте. Бу, кемнәрдер уйлаганча, артка чигенү түгел, киресенчә, үз позицияләребезне ныгыту иде. Билгеле, моны аңлап бетермәүчеләр дә булмады түгел. Президентка тәнкыйть уты да ярыйсы гына эләкте ул вакытта. Нишлисең, сәясәттә туры юлдан бару җиңел түгел шул. Бигрәк тә төрле якка тарткалый башласалар, һәр адымыңа шикләнеп карасалар…

Минтимер Шәймиев – бүгенге көндә Россиядәге иң күренекле сәясәтчеләрнең берсе. Аның фикеренә колак салалар, аның белән киңәшләшәләр. Аны хәтта Россия президентлыгына кандидат итеп күрсәтү турында да сүз кузгалганы бар. Ә нигә? Булдырыр иде. Ничек кенә әле! Дөньядагы башка бик күп илләрдә дә яхшы беләләр, иң югары дәрәҗәдә кабул итәләр аны. Моннан берничә ел элек ул рәсми визит белән Венгриягә барды. Рәсми делегациядә мин дә бар идем. Безнең Президентны ничек хөрмәт итүләрен үз күзләрем белән күрдем мин анда. Шул чагында Татарстаныбыз өчен, татар халкы өчен зур горурлык хисләре кичергәнем әле дә исемдә.

Күптән түгел Бакуда булганда да Минтимер ага Шәймиевнең халыкара абруена мин тагын бер кат ышанып кайттым. Чит илләрдән килгән язучылар, галимнәр белән очрашканда, Азәрбайҗан Президенты Гейдар Алиев белән сөйләшүләр вакытында Президентыбыз исеменә бик күп җылы сүзләр ишетергә туры килде. Баксаң, Татарстанны да, М. Шәймиевне дә яхшы беләләр, хәлләребез белән кызыксыналар, уңышларыбызга шатланып торалар. Ноябрь аенда булган иде безнең ул сәфәребез. «Татнефть» белән